**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** КАРАР

10 март 2023 ел **Чирмешән авылы** №60

«Чирмешән муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 17 мартындагы 92 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Чирмешән муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау турында» 2020 елның 17 мартындагы 92 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Преамбулада «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис)» сүзләренә алмаштырырга.

1.2 15.5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «15.5 Яктылык һәм башка төр маскировкалар буенча:

маскировкаланырга тиешле объектлар исемлеген билгеләү;

гражданнар оборонасы буенча төркемнәргә билгеләнгән тәртиптә каралган территорияләрне комплекслы маскировкалау планнарын эшләү;

яктылык һәм башка төр маскировкалар буенча чаралар үткәрү өчен кирәкле матди-техник чаралар запасларын булдыру һәм куллану өчен даими әзерлек хәлендә тоту;

билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы буенча төркемнәргә кертелгән территорияләрнең маскировкалары булмау билгеләрен киметү буенча инженер-техник чаралар үткәрү».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе Җамалетдинов И.М.